ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.11.2024 ел Баулы шәһәре №173

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 сентябрендәге 171 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга сату-алулар үткәрмичә генә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 24 августындагы 171 номерлы, 2024 елның 19 февралендәге 22 номерлы, 2024 елның 20 августындагы 113 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты:

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 сентябрендәге 171 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга сату-алулар үткәрмичә генә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 24 августындагы 171 номерлы, 2024 елның 19 февралендәге 22 номерлы, 2024 елның 20 августындагы 113 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

3 «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә

административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми билгеләр белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен, шул исәптән алар сорап мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, үз эченә алган вариантлары» бүлегендә:

3.3.3.4. пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«әлеге административ регламентның 3.3.3.1., 3.3.3.3. пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булганнарның пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.4.5. пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«әлеге административ регламентның 3.4.2., 3.4.4., 3.4.5. пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булганнарның пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.5.6. пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«әлеге административ регламентның 3.5.3-3.5.5 пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булганнарның пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.6.2. пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров